Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№22 (73)
4 июль 2013 ел

12+

## • Вакыйгалар эзеннән

**27 ИЮНЬ** көнне ректор **И.ГАФУРОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ РЕКТОРАТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Беренче булып, контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм якын арада булачак чаралар турында Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** сөйләде. Алга таба сүз структур яктан үзгәртелергә тиешле институтлар турында барды. Идарә итү һәм территориаль үсеш институты турында шул ук структур бүлекнең мәгариф эшләре буенча директор урынбасары **Е.ФАЗЛЫЕВА** мәгълүмат бирде. Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты һәм Тарих институтларын оптимальләштерү процессы турында Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтының директор вазифасын башкаручы **Р.ХӘЙРЕТДИНОВ** сөйләде. Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **С.ИОНЕНКО** КФУга кабул итүнең торышы белән таныштырды. Бу көнгә инде 7 меңнән артык абитуриент документлар тапшырган. ИТИС Югары мәктәбе директоры **А.ХАСЬЯНОВ** үзе җитәкли торган структур бүлекчәнең стратегик үсеш юллары турында сөйләде. Ректор әлеге мәктәптә, тәкъдим ителгәнчә, 4 кафедра түгел, ә өчне булдырырга кирәк, дип киңәш итте.

• • • •

Шул ук көнне **ГЫЙЛЬМИ СОВЕТНЫҢ ЧИРАТТАГЫ УТЫРЫШЫ УЗДЫ**. Н.И.Лобачевский ис. математика һәм механика институты директоры **В.ЧУГУНОВ** КФУдагы математик белем бирү концепциясе турында сөйләде, математика буенча БДИ нәтиҗәләре һәм КФУдагы рейтинглар турында мәгълүмат бирде. Гыйльми совет вәкилләре, IT-белгечләрне югары дәрәҗәдә әзерләү өчен, 4 кафедра булдырырга дигән тәкъдимне бертавыштан яклап чыктылар. Алга таба Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты һәм Тарих институтларының структурасын оптимальләштерү мәсьәләсенә туктадылар. Барлык тәкъдимнәр Гыйльми совет тарафыннан расланды. Идарә итү һәм территориаль үсеш институтының социаль өлкәдә сыйфат белән идарә итү кафедрасы Инженерия институтына күчәчәк. Идарә итү һәм территориаль үсеш институтында исә, социаль-икътисади системаларны прогнозлау һәм анализлау лабораториясе булдырылачак. Алга таба Гыйльми совет Педагогика һәм психология институтының кайбер кафедра исемнәрен үзгәртү турындагы тәкъдимнәрне кабул итте. Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институтында телевидение һәм тележитештерү кафедрасы, этносоциология һәм этносәясәт кафедраларын ачарга дигән карар кылынды. Утырышның ахырында финанс эшләре буенча проректор **Р.МУЛЛАКАЕВА** 2013 елның 1 сентябреннән университетыбызның югары һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган фәнни-педагогик хезмәткәрләргә түләү системасындагы үзгәрешләр турында сөйләде.

• • • •

**ТРның МАХСУС ДӘҮЛӘТ СТИПЕНДИЯСЕНӘ КОНКУРС ИГЪЛАН ИТЕЛДЕ**. Ул көндезге бүлектә белем алучы, уку һәм фәнни эшчәнлектә уңышларга ирешкән студентларга бирелә. Аңа түләүле бүлектә укучылар да дәгъва кыла ала.

• • • •

Алабуга институтында да **КАБУЛ ИТҮ КОМИССИЯСЕ** җиң сызганып эшли. Бүгенге көндә анда инде 1200дән артык гариза кабул ителгән.

• • • •

Кичә Универсиада волонтерлары **«СПОРТСМЕННАР ХЕЗМӘТЕН ХАЛЫКАРА-ХОКУКЫЙ ҖАЙГА САЛУ»** исемле лекция тыңладылар.

• • • •

**УНИВЕРСИАДА ВАКЫТЫНДА** «Спортивное совещание» автоном коммерцияле булмаган оешма ярышларны HD форматта күрсәтәчәк. Аны барлык федераль каналлардан һәм russiasport.ru сайтыннан карарга мөмкин булачак.

• • • •

**7 ИЮЛЬ** көнне «Волга» яшьләр үзәгендә башкалабызга бүтән төбәкләрдән килгән федераль университет ректорлары катнашында **ФУТБОЛ ЯРЫШЫ УЗАЧАК**.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*




# Универсиада килә! Универсиада!

Бөтен илебезне шаулаткан XVII Җәйге Универсиада башланырга да нибары ике көн калды.

Шәһәребез көннән-көн үсә, үзәрә. Бу масштаблы чара университетыбыз эшчәнлегенә дә йогынты ясамый калмады. Спорт корылмаларыбыз артты, заманча тулай торакларыбыз төзелде, спорт сөючеләр өчен яңа мөмкинлекләр ачылды, студентлар да, волонтерлар буларак, күпме уңай тәҗрибә туплый. Алай гына да түгел, һәркайсыбыз сәламәт яшәү рәвешенә ияләшеп бетте.

Иң кызу эш өсте Универсиада авылында бара. 29 июнь көнне бирегә ярышларда катнашачак спортчылар килә башлады. Беренче булып, Коста-Рика, бераз соңрак Яңа Зеландия, Япония һәм Уругвай вәкилләре килде. Кунаклар барысы да шул «авылда» торачак. Аларны өч мең ярым урынлы ашханәләрдә тукландырачаклар.

Шулай ук Универсиада авылында Россия җыелма командасының флагын күтәрү тантанасы да үтте. Ул флаглар аллеясында беренче булып күтәрелде. Безнең команда кеше саны күплеге белән аерылып торачак һәм Универсиада программасына кертелгән барлык ярышларда да катнашачак. Анда барлыгы 663 спортчы. Шуларның унбише – безнең университет студентлары. Гомумән алганда, чарага 162 илдән спортчылар киләчәк. Бу – Универсиада 2013 тарихында куелган рекордларның берсе.

Бүген исә, ачылыш тантанасында катнашу өчен, КФУга беркетелгән Россия югары уку йортларының ректорлары киләчәк.

Иң зур чараларның берсе булып, КФУда Универсиада утын каршы алу тора. 2012 елның 12 июлендә Сорбонна университетында (Франция) старт алган эстафета, ниһаять, безгә килеп җитә. Ул илебезнең 54 шәһәре аша узып, 50 эре студент үзәкләрендә булды һәм барлыгы 150 мең километрдан артык юл үтте. Россиянең 30 шәһәре, республикабызның 44 районы Универсиада утын кабул итте. Эстафета нәкъ менә бездә 6 июль көнне сәгать 11:00дә төгәлләнәчәк. Уку йортыбызның төп бинасы каршында узачак чарада тамашачылар өчен концерт программасы һәм конкурслар каралган. Ут, 11:30дан башлап, чара ачылганчы торачак. Бу тарихи вакыйгада һәр кеше катнаша ала.

Уку йортыбыз да Универсиаданы бөтен халыкка җиткерү, тарихка кертеп калдыру өчен бөтен көчен куя. Университетның «UNIVER TV» каналын хәзер бөтен Универсиада объектларында карап була. Студентлар телевидениесе спортчылар һәм махсус кунаклар өчен форматын да үзгәртте. Шулай ук «Казанский Университет» һәм безнең газета да сезне яңалыклар, спортчылар, әлбәттә инде, волонтерлар эшчәнлеге белән таныштырып торачак.

Универсиада вакытында узачак тагын бер зур чара турында әйтеп узарга кирәк. Безнең милли бәйрәмебез – Сабантуй, ел саен кабатланган традициясе үзгәртеп, студентлар уеннарының иң кызган чагында үтәчәк. Шулай итеп, бөтендөнья буенча җыелган кунаклар татар халкының иң зур бәйрәмен күрә алачак.

## • Универсиаданы якынайтып

# Казан буйлап - сәпиттә!

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

1 июльдә КФУның төп бинасы каршында беренче Veli'K шәһәр велопаркы челтәре ачылды. Универсиада алдыннан Казанда Cyclocity технологиясе буенча эшләнгән мондый парк шәһәр үзәгенең тагын 5 урынында ачылачак.

Veli'K – көн саен тәүлек буена эшли торган велопрокат челтәре. 16 яше тулган һәркем моннан прокатка велосипед алып тора ала. Мондый Veli'K терминаллары шәһәр үзәгендә берничә җирдә булачак. Алар бер-берсеннән артык ерак булмаган аралыкта урнашачак.

**Ахыры 2нче биттә.**



Диана Поварова фотосы

● Сәяхәттән кайткач

# Яшәсәк тә төрле җирләрдә...

**Лилия ЯКУПОВА,**
татар филологиясе бүлеге

Җәй, кояш, эссе көн һәм Сабантуйлар... Бу безнең турыда түгел! Чөнки без – татар филологиясе бүлегенең 1001 һәм 1002нче төркем студентлары әле күптән түгел генә сәяхәттән кайттык.

Татарстаныбыз шаулап-гөрләп Сабантуйларын бәйрәм иткәндә, кайда йөрдегез дисезме? Сер түгел, мөгаллимнәребез белән Пенза өлкәсе Каменка районының Кикино авылында диалектологик экспедициядә булдык. Ул – Пенза өлкәсендә урнашкан алты татар авылының берсе һәм, әйтергә кирәк, биредә халык бик күңелле яши.

Кикино авылы, татар авылы буларак беренче тапкыр, 1745 елда искә алына. Авыл халкын ногайлардан килеп чыккан дип санаучылар да, болгар нәселеннән дип әйтүчеләр дә бар. Ничек кенә булмасын, үз гореф-гадәтләренә тугрылык саклап, телне, динне яшь буынга сеңдереп яшәп ята Кикино халкы. Безне – Казан кунакларын да – алар татарларга хас ачык йөзле, тәмле сүз белән каршы алдылар, уңайлы итеп урнаштырдылар. Мәктәп директоры Фәрит Наил улы Девликамов бер генә үтенечебезне дә кире какмады. Әлеге авылда үткәргән беренче көннән үк, безне кайгыртып торган Кикино урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Равилә апа Баткаевага да рәхмәтебез бик зур. Аларның тырышлыгы белән бөтен юл газапларыбыз онытылды, авыл халкы белән мөнәсәбәтләр җылы булды, мәктәп коллективы да безне яратып каршы алды. Әлеге авылдан килеп укучы курсташыбыз Венера Давликамова да экспедициябез уңышлы булсын, дип янып-көеп йөрде: алдан ук авыл җитәкчелеге белән сөйләшеп куйды, безне Пензада ук каршы алып, өйләренә чакырып кунак итте.

Бу авылда үткәргән һәр көн төрле-төрле вакыйгаларга, очрашуларга бай булды. Шул бер атна эчендә без авыл халкы, мәктәп каршындагы лагерьга йөрүче балалар белән аралашырга да, Гайшә – Маһирә мәчете, якын-тирәдәге истәлекле урыннар белән танышырга да, күрше авылда оештырылган Келәүне күрергә дә өлгердек. Кайсы йортка гына керсәк тә, безне колач җәеп каршы алдылар, табынга утырттылар, кунак иттеләр, тагын килегез, дип озаттылар. Без кергән һәр өйдә җыр-моң яратучы, сүзгә оста кешеләр табылып кына торды. Алар хәтта шәхси әйберләрен дә кызганмыйча, тикшерү өчен безгә биреп җибәрделәр. Кикино халкы белән күбрәк очрашкан, якынрак танышкан саен, аларның ачык күңеллелегенә, ягымлы, ярдәмчел һәм, авылларының бик зур (1000гә якын хуҗалык) булуына да карамастан, бердәм булуларына сокланыбыз артканнан-арта барды. Аралашу дәвамында үзебез дә аларның сөйләмнәренә ияләшеп беттек, кайбер предметларны нәкъ алар кебек атый башладык. Мәсәлән, аш–ышти, кабартма–пипи, пирог – бәлеш һ.б. Әлеге үзенчәлекләр экспедициягә барган кызларыбызның фәнни мәкаләләрендә лаеклы урыннарны алыр дип ышанасы килә.

Казаныбызга кайтыр көн бик тиз килеп җитте. Китәр юлга җыенып чыкканда, озатырга дип без аралашып өлгергән әбиләр, апалар җыелган иде. Аларны күргәч, күңелгә шатлык тулды: яратканнар! Сабан туена да кайтыгыз дип, чакырып калдылар, хәерле юл теләделәр. Бик моңсу гына саубуллаштык.

Әлеге экспедициядә үткәргән көннәребез күңелдә җылы бер хатирә булып бик озак сакланыр. Әлбәттә, бу сәяхәтнең сәбәпчеләре, юлыбыз уңсын, дип чын күңелдән тырышып йөргән, безнең өчен ут йотып торган җитәкчеләребезгә – ФСИның татар теле тарихы һәм төрки телләр белеме кафедрасы укытучылары Фәнүзә Шәкүр кызы Нуриева һәм Энже Хәнәфи кызы Кадыйровага – зур рәхмәтебезне әйтәбез. Нәкъ менә Фәнүзә Шәкүровна һәм Энже Хәнәфиевнаның шундый тырыш, өлгер һәм җитез булулары уңышлы нәтиҗәләр бирде. Без бай диалектологик материал тупладык, Татарстаннан читтә урнашкан, әмма чын татар рухын саклап яшәгән авыл халкы белән күрештек, аралаштык. Кикино авылының үз тарихы, татар милләте үсешенә керткән үз өлеше, кунакчыл, киң күңелле халкы бар. Яшьләре дә тәртипле, ачык йөзлеләр. Димәк, авылның киләчәге дә якты, куанычлы булыр дигән өмет зур.







● Ачыш

# Казан буйлап - сәпиттә!

Башы 1нче биттә.

Әлеге велопарковкадан файдалану өчен, *veli-k.ru* сайтында теркәлү, үзең һәм кредит картасы турындагы мәгълүматны калдыру җитә.

24 сәгатькә, 7 һәм 30 көнгә абонемент алу мөмкинлеге тудырылган. Ярты сәгать эчендә икенче терминалга барып җитсәң, велосипедны шунда гына калдырсаң да була. Моннысы өчен кредит картасыннан өстәмә сумма алынмаячак. Бушлай йөрү вакытының алдагы сәгатьләре өчен аерым түләргә туры киләчәк. Беренче сәгать 50 сум булса, калган сәгатьләре 150шәр сумга төшәчәк. Әгәр велосипед 24 сәгать эчендә бер терминалга да кире кайтарылмаса, картадан 14000 сум акча алыначак. Бу – велосипед бәясе.

Терминал ярдәмендә велосипедсайларга, станцияләрнең урнашу урыбын һәм аларда буш велосипед бармы-юкмы икәнлеген карап була.

Cyclocity программасы беренче мәртәбә 2002 елда Австрия башкаласы Венада эшли башлый. Ни кызганыч, ул чакта тәүлек эчендә бөтен сәпитләрне дә урлап бетерәләр. Бездә мондый күңелсез хәлләр булмас, дип өметләнәбез. Казандагы Veli'K программасы җитәкчеләре сәпитләрне вандаллардан саклау каралган дип ышандыра. «Махсус техникадан башка велосипедларны сүтеп тә, ватып та булмый», – ди алар бер тавыштан.




инказан.ru

● Сәләткә сәбәп кирәк

«Яшь эшмәкәрләр» дигән сүзтезмә белән бүген бер кешене дә шаккатырып булмый, чөнки күп кенә өлкәләрдә әле 25 яшен дә тутырмаган талантлы белгечләр үз ширкәтләрен, оешмаларын ача. Әлбәттә, бу җинел эш түгел һәм ул билгеле бер өзерлек, белем таләп итә. Ә аны кайдан алырга? Бу сорауга җавап табар өчен, КФУның студентлар эшмәкәрлек инкубаторы эшчәнлеге белән танышырга булдым.

# Студентлар да эшмәкәр була ала

**Ләйсән ГАЛИУЛЛИНА,**
Гаммәви коммуникация
һәм социаль фәннәр институты

Аларның һәр җыелышлары идея, төрле-төрле фикерләргә бай була. Үзләре әле студент кына булган егет-кызлар әлеге берләшмәгә төрле максат белән килә. Берәүләр өчен бу – бары тик ниндидер кызыклы бер түгәрәк, икенчеләр исә, бирегә эшмәкәрлек буенча булган планнарын тормышка ашырыр өчен мәйдан эзли. Шундый актив студентлар саны 20-30 кешегә якынлаша.

Эшмәкәрлек инкубаторында җыелышлар 4 юнәлеш буенча уздырыла: белем бирү, практик дәресләр, файдалы ял итүгә юнәлдерелгән чаралар, консультацияләр. Еш кына яшьләргә тәҗрибәле белгечләр мастер-класслар үткәрә, студентлар үзләре дә даими рәвештә төрле эшмәкәрлек-кейслар ачу, икътисади уеннар уйнау белән шөгыльләнә. Финанс өлкәсенең «серләрен» ачу өчен, алар хәтта яңа проект куллана башлаганнар, аның исеме – «кинотренинг». Яшьләр, бергәләп кино карагач, аның аерым өлешләренә тукталып анализ ясый. Әлбәттә, фильм сайлауга да катнашучылар аерым әзерлек белән килә, чөнки аның нигезендә ниндидер яхшы яки тискәре, әмма гыйбрәтле мисал ятарга тиеш.

Оешма инде 2 ел дәвамында, КФУ мәйданында эш итә. Җыелышлар да, күбесенчә, университет бинабарында уза. Ярты ел элек булган сайлаулар нәтиҗәсендә, берләшмәгә яңа җитәкчелек билгеләнде, эш программасы төзелде. Бүгенге көндә эшмәкәрлек инкубаторын Никита Беликов җитәкли. Ул чынлап үрнәк алырдай кеше: әле 4 курсны гына тәмамлаган булса да, IT-ширкәтне оештыручыларның берсе булып санала. 2012 елда әлеге ширкәтнең нигезендә яткан проект «Татарстан республикасы өчен иң яхшы 50 инновацион идея» бәйгесендә грант алды. Хәзерге вакытта, Никита хезмәттәшләре белән мәгариф өлкәсе өчен «Полития.ру» онлайн-уен эшләп чыгару белән шөгыльләнә. Башка тормышка ашырылырлык идеяләре дә күп аның. Оешма белән ул җитәкчелек иткән вакыт аралыгында, актив катнашучыларның 6 эшмәкәрлек-проекты гамәлгә кертелде. Студентлар аерүча яратып IT-технологияләр, сәүдәгәрләр, хезмәт күрсәтү өлкәләре буенча проектлар төзи. Алия, мәсәлән, чәчәк сату белән шөгыльләнә. Аның өе янында матурлык тәкъдим итә торган 4 сату ноктасы бар; ул шулай ук көндәшләр белән көрәшү юлын тапкан – Интернет-кибет ачып җибәргән. «Мондый формат миңа чыгымнарны киметергә булыша һәм шуңа күрә чәчәкләрне дә, башкалар белән чагыштырганда, арзанрак бәягә сата алам», – ди яшь сәүдәгәр.

Студентлар эшмәкәрлек инкубаторы – ул зур, талантлы, дус команда. Бу турыда яшьләрнең активлыгы да әйтеп тора. Алар даими рәвештә төрле республика һәм Россия күләмендә уздырылган ярышларда, форумнарда, конференцияләрдә катнаша. Күптән түгел КФУның студентлар эшмәкәрлек-инкубаторы Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институтының OECO-MOMICUS исемле икътисади клубы белән хезмәттәшлек буенча килешү төзегән. Ул берләшмә эшчәнлегенең тагын да алга китүенә этәреш булачак.

● Тарих сәхифәләреннән

# Төп Коръән бездә саклана!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Күп гасырлар дәвамында мөселманнарның изге китабы Коръән телдән һәм кульязма рәвешендә сакланып килгән һәм таралыш алган. Кульязма күчермәләрен бары тик иң яхшы каллиграфлар гына эшләгән, изге текстның бизәлешен үз эшләренең осталары гына башкарган.

Ислам тарихында озак вакытлар дәвамында Коръәннең басма вариантлары Европада гына була, ә Көнчыгышта ул алай актуаль саналмый. Россиядә исә, гарәп телендәге Коръән Екатерина II указы буенча 1787 елда чыгарыла. Кайбер чыганакларда әлеге басма, кыргызларга бушлай өләшер өчен, Санкт-Петербургта бастырылган дигән мәгълүмат очрый. Алар Стамбулда 25-50 сумнарга сатылган.

1800 елның 25 маенда Павел I Шнор типографиясен Казан гимназиясенә күчерергә дигән карар чыгара һәм, шулай итеп, ул Казан гимназиясе бинасында урнаштырыла. Типография бары гарәп графикасы шрифтларына гына ия булганлыктан, аңа «Азия» дигән исем бирелә һәм ул беренче мөселман типографиясе буларак кабул ителә.

Типографиянең хуҗасы итеп Габделгазиз Туктамыш улы Бурашев сайлана, Петербургтан типография белән бергә килгән Казан татарлары Гали Рахматуллин һәм Хәмзә Мамышев анда эшчеләр (текст җыючылар) булып урнашалар.

Типография инде 1800 елның 20 октябрендә үк Казанга күчерелсә дә, цензура рөхсәте булмаганлыктан, китаплар 1801 елның февралендә генә дөнья күрә башлый. Коръән текстының дөреслеген һәм төгәллеген билгеләү өчен, Иске Татар бистәсе мәчете имамы Мөхәммәд Абрразяковка мөрәҗәгать итәләр, ә калган китапларны тикшерү Оренбургтагы мөфтигә йөкләнә.



Сынау өчен алынган китапларны җыеп бетергәннән соң, типография иң җаваплы эшкә – Коръәнне тулысы белән яңадан бастыруга алына.

Коръән укуны җиңеләйтү өчен, аның элеккеге форматы хәйран үзгәртелә. Зур форматлы бер томнан ярты битлек ике том булдырыла һәм, иң мөһиме, Коръән укылышының каноник традицияләрен боза торган текст кырыйларындагы шәрехләүләрдән баш тартыла.

Шул ук вакытта, уникаль һәм алга таба кулланылыш тапмаган бик кечкенә форматтагы китап өчен текст җыелмасы да әзерлиләр. Текст 30 өлешкә бүленгән була, һәр томга өчәр туры килә. Ун томлык кечкенә форматтагы басма алдан ук балалар өчен дип эшләнелә. Ул бер меңлек тираж белән чыга һәм безгә аларның дүртесе генә килеп җиткән.

1803 елдан Коръәннең ике томлык басмасы Россия империясенең көнчыгыш өлкәләрендә һәм мөселман дәүләтләрендә киң тарала башлый.

Алдагы елларда Коръәннең һәр елда бастырылган басмаларының тиражы, мең ярымнан алып, өч меңгә кадәр җиткән һәм алар бик тиз таралып бетә торган булганнар. 1806 елга инде башка типографияләр дә элеккеге, «Петербург варианты» Коръәнне, елын һәм бастырылу урынын күрсәтмичә генә чыгара башлыйлар.

Коръәннең һәрдаим бастырылуы Казан гимназиясе каршындагы типография университетныкы белән кушылганнан соң да (1829 ел) дәвам итә. Бу вакытка инде Коръәннең мөселманнар арасында «Казан басма» дип йөртелә башлаган басма тексты классик дип санала башлый. Бу Урта Азия, Төркия, Якын Көнчыгыш мөселманнары арасында бик популяр була. Нәкъ шушы текст вариантының классик булып танылуы һәм Европа ориенталистлары тарафыннан югары бәягә лаек булуы очраклы хәл түгелдер. Коръәннең мөселман территориясендә, Казанда басылганы беренче мөселман басмасы буларак кабул ителә.

Изге китап XIX гасырга кадәр Көнчыгыш: Төркия, Мисыр һәм Һиндстанда күп итеп басылган, барлыгы 150 мең экземплярда дөнья күргән. Нәтиҗәдә, нәкъ менә Казан Коръәннәре хәзерге Коръәннең тулы образын булдыруга ярдәм иткән.

2005 елның июнендә Казан шәһәре мэрының инициативасы һәм актив булышлыгы ярдәмендә, 1803 елгы Казан Коръәне, шул хәлендә яңадан бастырылып, халыкка тәкъдим ителде. Аның презентациясе татар халкының тарихи үткәнен бүгенгесе белән бәйли торган мизгелгә – Кол Шәриф мәчетен ачу көненә туры китерелде.

*1803 елгы Казан Коръәне – бик сирәк хәзинә. Россиядә аның бер генә экземпляры сакланып калган. Ул Казан университетының китапханәсендә саклана. Ике тулы басма Казан федераль университеты китапханәсендә һәм Бавар Милли китапханәсендә; ике тулы булмаганының берсе шулай ук бездә, икенчесе Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институтының Санкт-Петербург филиалы китапханәсендә саклана.*

*Н.И.Лобачевский исемендәге китапханәнең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге мәгълүматлары файдаланылды.*

● Галиҗәнап китап

✓Дөньядагы **иң зур китап** – Мисырдагы бер гыйбадәтханә стенасына уелып язылган елъязма. Аның таш «битләре»нең киңлеге 40 метр.

✓Кәгазьгә басылган **иң калын китап** – 8048 битле Библия. Авырлыгы 500 килограммлап булган бу китап Америкада саклана.

✓ Ә **иң бәләкәй китап – Япониядә.** Асао Хосимо авторлыгында чыгарылган бу китапның озынлыгы – 1,4мм, ул 20 биттән тора.

✓Лондон шәһәренең **«Фойлз»** китап кибете **басма продукциясенең күплеге** белән дан тота. Китап киштәләренең озынлыгы – 48 км, кибетнең мәйданы – 7044 м².

✓**Иң авыр тарихи китапларның берсе – әрмән телендә.** «Муша монастыре вәгазьләре» кульязмасы. Ул бер пот авырлыгында булган. 1204 елда китапны басмачылар урлап киткән. Кульязма Муша (Көнбатыш Әрмәнстан) шәһәрендә 7 гасырдан артык вакыт сакланган. 1915 елда төрекләр һөҗүменнән качучы әрмәннәр халыкның бу рухи хәзинәсен үзләре белән алганнар. Кульязма ахыр чиктә Әрмәнстанның төп китап саклау үзәгенә – Матедаранга килеп эләгә.

✓1832 елда Лондонда **«Инглиз геройлары җыелмасы»** дигән китап 100 данәдә басыла. Аның озынлыгы – 7 метрдан артык, ә киңлеге 4 метрга якын була. Хәрефләрнең зурлыгы 15 сантиметрдан артык. Ул дөньядагы иң авыр басма исәпләнә.

✓1899 елда Варшавада, А.С.Пушкинның тууына 100 ел тулуга багышлап, күләме 28гә 18 мм тәшкил иткән **«Евгений Онегин»** поэмасы басыла. Аның һәр битенә 30 юл сыйдырылган китапчыкны медальонга урнаштырырга була. Медальон капкачының уртасына, китапчыкны укыр өчен, линза беркетелгән.

✓1455 елда **Гутенберг тарафыннан басылган Библия** – дөньяда иң кыйммәтле китап булып санала. 1926 елда аның бер данәсе 350 мең долларга сатыла.

✓1633 елда **Лондонда басылып чыккан китапка иң-иң озын исем бирелгән.** Ул 45 юлдан тора.

● Белем буразналары

# Яңача өйрәнәбез!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Шушы көннәрдә КФУның Тарих институты профессоры Альберт Борһанов җитәкчелегендәге фәнни төркем Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнарына җирле төбәкнең һәм торак пунктларның тарихын барлау, археологик һәм эпиграфик һәйкәлләрне өйрәнү максатыннан экспедициягә чыгып китте.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тарих институты һәм КФУның уртак булган Алтын Урда комплексы тарихи-археологик экспедициясе инде 1995 елдан бирле Татарстан районнары, Әстерхан өлкәсе һәм Урта Азия якларындагы борынгы һәм урта гасыр һәйкәлләрен өйрәнү эшләре алып бара. Экспедиция нәтиҗәсе буларак, кырыкка якын китап, монография һәм мәкаләләр җыентыгы дөнья күрде, утызга якын төбәкара һәм халыкара фәнни-гамәли конференцияләр үткәрелде.

Экспедициядә танылган галимнәр, яшь белгечләр һәм аспирантлар, Казан, Бөгелмә, Әлмәт югары уку йортлары студентлары, мәктәп укучылары катнаша.




А.Борһанов сүзләренә караганда, төп игътибар урта гасыр күчмә халык мәдәнияте белән бәйләнешле булган археологик объектларга, Ык елгасы һәм аның кушылдыклары бассейны тирәсендәге утрак халыкның зират һәм корылма калдыкларын өйрәнүгә бирeләчәк. Монда тупланган мәгълүмат ТР көнчыгыш районнарының борынгы, урта һәм яңа тарихын яңа сулыш белән өйрәнергә мөмкинлек бирәчәк.

● Яңа китап

Күптән түгел «Азнакай. Азнакай тарихы һәм кешеләре турында очерклар» исемле яңа китап дөнья күрде. Ул ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре, язучы Марсель Гарипов җитәкчелегендә берничә автор тарафыннан әзерләнеп, Азнакай муниципаль районы администрациясе башлыгы М.З.Шәйдуллин ярдәмендә бастырылды.

# Гасырлар тарихы буйлап





Китап фәнни-популяр стильдә язылган һәм күпсанлы төсле фотосурәтләр белән бизәлгән. Мәгълүматны татар һәм рус телләрендә уку мөмкинлеге бар, һәр бүлекнең аннотациясе төрек һәм инглиз телләрендә язылган.

Биредә Казан университеты галимнәре турында да мәгълүмат бар. Мисал өчен, «Азнакай шәһәренең мактаулы кешеләре» дигән бүлектә КФУ профессоры, Татарстан Республикасының Фәннәр академиясе академигы, РФ һәм ТРның атказанган фән эшлеклесе, тарих фәннәре докторы Индус Таһиров турында язылган.

«Гасыр артыннан гасыр» бүлегендә Азнакай җирләренең тарихына күзәтү ясала. Биредә КФУның Тарих институты профессоры, археолог Альберт Борһановның «Борынгы һәм урта гасыр тарихы буйлап» исемле мәкаләсе дә урын алган. Галим аны 2010 елда Азнакай районының археологик һәм эпиграфик һәйкәлләрен өйрәнүгә багышланган беренче киң масштаблы тикшеренүләр һәм инде булган материалларга нигезләнеп язган. Сүз уңаеннан, 2013 елда Альберт Борһанов җитәкчелегендә Азнакай һәм Ютазы районнарында, шулай ук киң масштаблы тикшеренүләр башкарылачак. Шуның нәтиҗәсе буларак, фәнни монография бастырылачак.

Китапның презентациясендә КФУ, ТР Фәннәр академиясе галимнәре, язучылар һәм журналистлар катнашты. Газета укучы дусларыбыз, әгәр сез Азнакай яклары белән кызыксынасыз, белемнәрегезне арттырырга телисез икән, әлеге китапны үзегездә булдырырга ашыгыгыз!

● Абитуриентлар өчен

# КФУда укы һәм ике дипломлы бул!

**Ләйсән ИСХАКОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Дөньяви фәннәр белән ничек якынаерга? КФУ студентлары өчен мондый проблема бөтенләй юк. Ник дигәндә, Казан университетында берничә икеләтә диплом программасы эшләп килә.

Икътисадтагы соңгы үсеш юнәлешләре турында белергә Икътисад һәм финанс институты базасында оешкан КФУ – SUNY (Нью-Йорк штатының дәүләт университеты) **икеләтә диплом системасы** буенча укыту үзәге ярдәм итә. Financial Services (финанс уңайлыклар) дип аталган белгечлекне сайлаган алты кеше инде укуын тәгәлләп, берьюлы ике бакалавр дәрәҗәсен алды. Тагын илленәп студент укуын дәвам итә.

Бер елыңны Франциядә үткәрү һәм француз филологиясе өлкәсендә уңыш казану – Филология һәм сәнгать институты студентлары өчен хыял гына түгел! Болар – КФУ һәм **«Париж III – Яңа Сорбонна»** университетлары хезмәттәшлеге һәм «филологик белем, бакалавриат» дип аталган икеләтә диплом программасы нәтиҗәсе. Хәзерге этапта әлеге дипломга инде 4 кеше ия булды. Бүген Казан университетының француз филологиясе кафедрасына караган берничә студент «Париж III – Яңа Сорбонна» университетында белем эсти.



А.Бәдретдинов (уңда) фәнни җитәкчесе профессор К.Коно һәм профессор Д.Таюрский белән

Узган елдан бирле КФУда **Страсбург университеты** белән берлектә хемоинформатика буенча магистр программасы эшләп килә. Бу программаны уңышлы үзләштергән студентлар да ике – Казан һәм Страсбург университеты дипломнарын алачак. Гомумән, хемоинформатика – химия һәм химик технологияләр өлкәсендәге мәгълүматны оптималь чишелешләр кабул итәрлек белемгә үзгәртеп коруга нигезләнгән теоретик химиянең бер өлеше. Россиядә бу өлкәдәге белгечләрне бары тик Казан университетында гына әзерлиләр!

Быел беренче мәртәбә Идарә һәм территориаль үсеш институтында **Гиссен университеты** (Германия) белән берлектә оештырылган «Transitional management» (күчеш чоры менеджменты) магистр программасына студентлар туплау уздырылачак. Авыр вакытларда да яхшы идарәче булып калырга өйрәнәсең килә икән, рәхим ит!

КФУ – Идел буе регионында берьюлы ике гыйльми дәрәҗә: Россия һәм **RIKEN** (**Япония**, Вако шәһәре) университетының PhD дәрәҗәсен бирә торган бердәнбер югары уку йорты. Беренче тапкыр бу мөмкинлектән КФУ, Физик һәм химик тикшеренүләр институты (RIKEN Япония, Вако шәһәре) аспиранты Александр Бәдретдинов файдаланды. Өч елда аңа берничә мәртәбә Казан-Токио арасын узарга туры килде. Ике ил, диссертациянең ике гыйльми җитәкчесе... Нәтиҗәсе дә күз алдында: ул Россиянең физика-математика фәннәре кандидаты исеменә һәм RIKEN университетының PhD дәрәҗәсенә лаек булды.

● Уңыш сере

# Алма агачыннан ерак төшми...

**Илмира АХУНОВА,** Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

Һөнәр сайлаган вакытта әти-әнисе юлыннан китүчеләр бик күп. Хәзерге заманда андыйларга карата «әтисе кушканга шунда эшли», «эш рәте белмәгәнгә, әтисе танышлары аша урнаштырган» дигән сүзләр еш ишетергә була. Чыннан да, үз һөнәрен профессиональ дәрәҗәдә белмәүче, әтисе ярдәме белән генә эшләп йөрүчеләр шактый бүген. Тик әнә шул әти-әнисе һөнәрен үз итеп, менә дигән белгеч, шәхес, хезмәткәр булып китүчеләр дә очрый. Аеруча иҗат белән бәйле һөнәр ияләренә кагыла бу. Чөнки берсенди сәләтсез, әти-әнисенең акчасы белән генә халыкның яраткан җырчысы да, журналисты да, шагыйре дә, биючесе дә, артисты да булам димә. Андый «йолдызлар», гадәттә, озак балкымый. Халык мәхәббәтен үз көчләре белән яулап алганнар булачак һөнәрләрен сайлаганда, әти-әниләренең өлеше нинди булган? Карьера баскычыннан күтәрелгәндә, әти-әниләренең исем-дәрәҗәсе ярдәме сизелгәнме? Әти-әниләре янына киңәш сорап еш киләләрме икән?

**АЛМАЗ ГАФИЯТОВ – журналист (әтисе «Татарстан яшьләре» журналисты Атлас Гафиятов):** «Журналист гаиләсендә үсү үз эшен башкаргандыр. Әти янына һәрвакыт танылган журналистлар килә иде, аларның әңгәмәләре тәэсирендә үстем. Редакциягә ияреп барган чаклар да күп булды. Аннары, минем яшьтәге балалар әле укый-яза белмәгәндә, көн саен калын-калын газет-журнал укып утырган малайны күз алдына китерәсездер. Ләкин һөнәрне сайлаганда, бары тик үз фикеремә генә нигезләндем. Бер яктан әти исеме ярдәм итсә, икенче яктан, киресенчә, авыр йөк булып тора. Өстәвенә, зур җаваплылык та. Әтигә күбрәк тормыш мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать итәм.

**АЙГӨЛ БАРИЕВА – җырчы (әтисе Татарстанның атказанган артисты, киноактер, режиссер һәм педагог Шамил Бариев):** «Булачак һөнәремә, ягъни артист яки җырчы булуыма, әти-әни һәрвакыт каршы иде. Гомумән, кечкенәдән үк хатын-кыз өчен гаилә бәхете – иң мөһиме, дип үстерде алар мине. Ләкин мин сәхнә артында үскән бала. Шуңа күрә үземне сәхнәдән башка күз алдына да китерә алмадым. Тик минем, бигрәк тә, киноактриса буласым килә иде. Аңа Мәскәүдә генә укыталар. Ә мине әти-әнием җибәрмәде. Институтка керер алдыннан, кайсында математика юк, шунысына керергә теләдем. Сәнгать институтына шулай килеп эләктем дә. Һәм бер дә үкенмим... Күп вакыт «Ә ул Шамил Бариев кызы, шуңа күрә аны бөтен җиргә үткәрәләр», – дигән сүзләр ишетергә туры килде. Ләкин тамашачының күңелен «Әти кызы» буларак кына яулый алмыйсың шул.

**ИЛНАЗ САФИУЛЛИН – җырчы (әтисе җырчы һәм композитор Зиннур Сафиуллин):** Булачак һөнәремне, кайда укырга керергә теләгәнемне мин мәктәпне бетергәндә үк белә идем инде. Әдәбият, телләр, математика буенча иң көчлеләрдән идем. Шуңа да математиканы сайлап укырга кердем. Минемчә, әти-әнисе нинди генә дәрәҗәле кеше булмасын, әгәр баланың үзендә, аңында юк икән, уңай нәтиҗә көтәргә кирәкми. Мин беренче елны, әлбәттә, әтиемнең кем икәнен яшерергә тырыштым. Хәзер үкенәм. Киресенчә, әтием белән горурланып, аны үземнең концертларыма чакырам. Ләкин төгәл беләм: әтинең исемен ниндидер максатка ирешер өчен кулланганым юк. Әти-әни сүзләренә колак салам. Тик үземчә эшлим. Калганнарга да шулай киңәш итәм.

**НӘФИСӘ ХӘЙРУЛЛИНА – актриса (әнисе Татарстанның халык артисткасы Фирдәвес Хәйруллина):** «Әнием булачак һөнәремә каршы иде. Ул мине өй кошы итеп үстерде. Куркак, юаш һәм үз-үзенә бикләнгән бала идем. Шуңа да актриса булырга миңа беркем дә ярдәм итмәде. Артымнан этүче, «минем кызым иң яхшысы», – дип йөрүче дә булмады. Студент чагымда мине әни белән чагыштырырга яраталар иде, чөнки без кыяфәт буенча бик охшаган. Бүген исә, безнең турыда ике аерым шәхес буларак сөйлиләр. Төннәрен еш кына әниемнән ярдәм сорыйм. Янымда булмаса да, аның ярдәмен тоеп яшим.

Әти-әниләреннән үрнәк алып, шулай да үз стильләрен, үз йөзләрен табарга тырышып атлый алар. Инде барыбызга да таныш булган «Татар радиосы» ди-джее Гөлназ Сәфәрова (әтисе «Ватаным Татарстан» газетасы редакторы Миңназыйм Сәфәров), Ләйсән һәм Фәрит Таишевлар (әниләре җырчы Римма Ибраһимова) һәм башкалар «әти кызы» яисә «әни улы» буларак түгел, ә талантлары аркасында халыкка танылды. Сүз дә юк, кечкенәдән шундый мохиттә үсү дә үз ролен уйнамый калмагандыр, аннары кечкенәдән баланың әти-әнисенә охшарга тырышуы да бар. Ни дисәң дә, алма агачыннан ерак төшми.

● Сәламәтлек



# «Кыю» бөҗәк

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

Җәйнең иң матур, кызган чагы... Тау битләрендә җиләк пешә, болыннар шау чәчәктә утыра. Моннан да рәхәт вакыт бармы икән? Бер әйберне онытмасак иде: җәй көне ай-һай күп соң безгә төрле яклап һөҗүм итәргә әзер торучылар.

Табигать безне серле кочагына дәшсә дә, законнарын, үзенчәлекләрен онытырга ирек бирми. Шул уңайсызлыклар аркасында, күпләрнең күңелендә җәй бөтенләй тискәре тәэсирләр калдыра. Аларның иң киң таралганы – бал корты. «Кысык күзле кеше булырга теләсәң, бал кортына «мөрәҗәгать ит», – дип тә шаяртып куялар кайчак. Ул берничә секунд эчендә синнән «япон кешесен» ясый да куя. Бал корты чаккан кеше кызык күренсә дә, бу хәл бик аянычлы тәгәлләнергә мөмкин. Шуңа күрә бал корты чакса, «төзәлер әле», – дип аның турында онытырга ярамый. Шунда ук беренче ярдәм күрсәтергә ашыгырга кирәк.

Бал корты чаккач, беренче чиратта, каушап калмаска, тынычлыкны сакларга кирәк. Башта кортның угын тартып алыгыз һәм яраны кан чыкканчы чистартыгыз, шул урынга салкын әйбер куеп, авыруга күп итеп су эчертегез. Бу организмга кергән агуны чыгарырга ярдәм итәр. Әгәр корт күз-авыз тирәләрен чакса, кеше шешенеп, сулыш алу кыенлашырга мөмкин. Бу очракта, бертуктаусыз салкын су эчү коткарачак. Моның белән беррәттән, кешенең тән температурасы күтәрелергә, тыны кысылырга, йөрәк тибеше ешаерга мөмкин, авыруның хәтта шок хәлендә калуы, һуштан язуы бар. Шөпшә чакканда, угын калдырмый һәм ул берничә тапкыр чагарга мөмкин. Ике очракта да яраны спирт белән юып, бу урынга боз куярга кирәк. Ул авыртуны баса һәм шешенүдән саклый. Спирт урынына бака яфрагы яисә суган согы, уксус, лимон согы кулланырга була. Тиз арада табибка күренсәгез, тагын да яхшырак булыр.

Аллергияле кешеләргә күпкә игътибарлырак булырга кирәк. Аллергиянең дә үзенә генә хас холкы бар һәм ул көтелмәгән үзенчәлекләре белән аерылып тора. Табиблар җәй көннәрендә үзең белән супрастин даруын, чиста су йөртергә тәкъдим итә. Табиблар әйтүенчә, корт чагуга аллергия күбрәк 12 яшькә кадәрле балаларда һәм хатын-кызларда була, шулай ук көнкүреш химиясенә, кайбер азык-төлеккә аллергиясе булган кешеләр корт чагуны авыр кичерә. Шунсы кызык: мондый кешеләрдә балга аллергия булмый икән.

Үзебездән башка безне беркем дә тулысынча саклый алмый. Аеруча җәйге эссе көннәрдә безнең организм индивидуаль караш таләп итә. Җәйне күңелле һәм сау-сәламәт уздырырга теләсәк, бар нәрсәгә игътибарлы булып, үз-үзеңә һәм тирә-юньдәгеләргә кирәк вакытта ярдәм кулы сузу турында онытмыйча, «кыю» бөҗәкләр алдында куркып калмасак иде.

DARELFØNYN университет
Тираж 500
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ЖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.